МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.07.2020 г.Казань № 514.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 11 августында 6812 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы «Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән (10.08.2016 ел № 465, 14.05.2018 ел № 363, 10.10.2018 ел № 935, 22.01.2019 ел № 45, 03.04.2019 ел № 226, 05.08.2019 ел № 595, 23.10.2019 ел № 888 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән)

расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына китерелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр вазыйфасын башкаручы Р.Ф. Валиуллов

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2020 елның
14 июлендәге 514 номерлы
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы «Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелгән үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.2 пунктта «гаиләнең җан башына кереме» сүзләрен «айлык уртача керем күләме» сүзләренә, «гаиләнең (гражданның) кушымтада билгеләнгән мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк» сүзләрен «кушымтаның «а»-«г», «е», «ж» пунктларында билгеләнгән мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк» сүзләренә алмаштырырга;

1.4.1 пунктның алтынчы абзацында «Министрлык» сүзләреннән соң «Интернет» челтәрендә» сүзләрен өстәргә;

1.4.2 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru). Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә.»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитлары һәм рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гариза (алга таба - гариза) астында 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" Федераль законның 2 маддәсенең 2 п. (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) юелән каралган дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гариза бирүченең соравы аңлашыла. Гариза формасы әлеге Регламентның $1^1$ нче кушымтасында бирелгән.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Стандарт таләпләре эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә кую | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы "Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында" карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибе (алга таба - ТР МК 97 номерлы карары белән расланган Тәртип). |
| 2.2. Башкарма хакимият органының атамасы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яисә шәһәр округындагы гариза бирүченең тору урыны буенча социаль яклау идарәсе (бүлеге) | ТР КМ 97 номерлы карары белән расланган тәртип |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту) турында карар | ТР КМ 97 номерлы карары белән расланган тәртипнең 2.2.2 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү | Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына | ТР КМ 97 номерлы карары белән |

| | | |
|---|---|---|
| вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, әгәр бу Россия Федерациясе законнарында каралса, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты | юллама алу өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту) турында карар гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәгән көннән алып ун көн эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту) турында кабул ителгән карарны хәбәр итү ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту) турында карар кабул ителгән көндә гамәлгә ашырыла | расланган тәртипнең 2.2.2 п. |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен һәм аны күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне алу өчен гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны гариза бирүче тарафыннан, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны бирү тәртибе | Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә куелу өчен түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:<br>1. Әлеге Регламентка $1^1$ нче кушымтада китерелгән форма нигезендә ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итүгә гариза;<br>2. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2014 елның 15 декабрендәге 834н номерлы «Амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында кулланыла торган медицина документларының унификацияләнгән формалары һәм аларны тутыру тәртибе турында» боерыгы белән расланган 070/у формасы буенча шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен белешмә;<br>3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 97 номерлы карары белән расланган Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән тәртиптә гариза бирүченең | ТР КМ 97 номерлы карары белән расланган тәртипнең 2.1 п.; |

уртача айлык кереме күләмен санаганда исәпкә алына торган, гариза биргән айга кадәрге өч ай эчендә гариза бирүченең керемнәрен раслый торган документлар, Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турындагы белешмәләрдән тыш;

4. Хокуклары Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында (алга таба - БДКМР) теркәлмәгән күчемсез милек объектларына хокук билгели торган документларның күчермәләре (булган очракта);

5. Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында бирелгән исемлектә күрсәтелгән һәм гариза бирүче белән законнар нигезендә бергә яшәтми торган хроник авыруның авыр формасы булуын раслаган белешмә (гариза бирүчедә андый авыру булган очракта).

6. Паспорт яки шәхесне таныклаучы башка документ.

Гариза бирүчеләр тарафыннан вәкиллек бирелгән затлар өстәмә рәвештә гариза бирүченең мәнфәгатьләрен белдерүне раслый торган документларның күчермәләрен тапшыра.

Документларның күчермәләре, Россия Федерациясе законнары нигезендә расланмаган очракта, оригиналларны күрсәтеп, тапшырыла һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан раслана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа кушып бирелә торган документларның күчермәләре (шәхесне раслаучы документның күчермәсеннән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә расланырга тиеш.

Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын гариза

| | | |
|---|---|---|
| | бирүче үзенең тору урыны буенча Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза бирүчеләргә гариза бирү ысулын сайлау мөмкинлеге тәэмин ителә: Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать итеп, почта аша яисә электрон документ рәвешендә, шул исәптән Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына караган оешмаларның карамагында торган һәм гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга мөмкин | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр кабул ителә:<br>шәхси исәп-хисап счетының иминият саны (СНИЛС) турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);<br>«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында вәкаләтле оешмалардан белешмәләр;<br>гариза бирүченең гаилә составы турында вәкаләтле оешмалардан белешмәләр;<br>Россия Федерациясе Пенсия фондында булган | ТР КМ 97 номерлы карары белән расланган тәртипнең 2.2 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләрнең аларны, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә башка оешма | керемнәр турында белешмәләр;<br>күчемсез милек булуы турында белешмәләр;<br>транспорт чараларының, үзйөрешле транспорт чараларының һәм башка төр техниканың булуы турында белешмәләр;<br>торак урынны билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану турында белешмәләр;<br>шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында белешмәләр (мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң) (вәкаләтле оешмалардан).<br>Гариза бирүче югарыда күрсәтелгән белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы.<br>Күрсәтелгән белешмәләр гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан, шул исәптән электрон рәвештә алынырга мөмкин.<br>Иадрә (бүлек) гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел: дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә аларны гамәлгә ашыру каралмаган гамәлләрне гамәлгә ашыру өчен документлар һәм мәгълүмат бирүне;<br>210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар | |

| | | |
|---|---|---|
| | карамагында булган дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен түләү кертүне раслаучы документларны һәм мәгълүматларны;<br>№ 210-ФЗ Федераль законның 7 маддәсендәге 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат бирүне.<br>Гариза бирүче күрсәтергә хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм бирү тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын тапшыру.<br>2. Әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның вакыты гамәлдән чыккан килеш тапшыру | ТР КМ 97 номерлы карары белән расланган тәртипнең 2.3 п. |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.<br>Юллама алу өчен хисапка куюдан баш тарту өчен | ТР КМ 97 номерлы карары белән расланган тәртипнең 2.4 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | нигез булып тора:<br>1. Гариза бирүченең әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмавы яки тулы булмаган пакетын тапшыруы;<br>2. Вакыты гамәлдән чыккан документларны тапшыру;<br>3. Гариза бирүченең уртача айлык кереме зурлыгының Татарстан Республикасында пенсионерның яшәү минимумы итеп билгеләнгән күләмнән 400 процентка артуы;<br>4. 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а»-«г», «е», «ж» пунктларында һәм ТР МК 97 номерлы карары белән расланган Тәртипнең 1.2 пунктындагы икенче һәм өченче абзацлары нигезләмәләрендә билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән гариза бирүченең өстен булу;<br>5. Гражданның Татарстан Республикасы чикләреннән чыгып китүе;<br>6. Гражданның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә шифаханә-курорт дәвалавына хокукы булган халык категорияләренә каравы | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап алганда һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны биргәндә һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратның максималь вакыты 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүгә аерым категориядәге гариза бирүчеләр өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указының 1 п. (алга таба Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы) |

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Гариза бирүченең хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәте һәм хезмәтләр күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада, гариза бирүченең соравын теркәү вакыты һәм тәртибе | Гариза белән документлар кергәннән алып бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән сорау әлеге ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә теркәлә | ТР КМ 97 номерлы карары белән расланган тәртип |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорауларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү, шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда башкарыла.<br>Инвалидларның хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз үтеп керү мөмкинлеге, шул исәптән объектларга киртәләрсез керү һәм алардан чыгу, шулай ук хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелгән объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. 210-ФЗ санлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), башкарма хакимият органының теләсә кайсы Территориаль бүлекчәсендә дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге йә мөмкин булмавы, | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуын күрсәтү билгеләре булып түбәндәгеләр тора:<br>Идарә (бүлек) биналарының җәмәгать транспортына якын урында урнашуы;<br>кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итәлә торган бүлмәләр булу;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакыты турында тулы мәгълүматның булуы;<br>инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтләрен алырга һәм алар күрсәтелгән урынга барып җитәргә комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты булып түбәндәге күрсәткечләре булып тора:<br>документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>гаризаны электрон формада бирә алу мөмкинлеге;<br>Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуы турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән үзара хезмәттәшлеккә керү саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе;<br>Россия Федерациясе Президентының 601 санлы Указының 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итүченең теләге буенча (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорау ярдәмендә (комплексы сорау) | тапшырганда турыдан-туры - бердән дә артмаган (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә - бердән дә артык булмаган (консультацияләрне исәпкә алмыйча), ә мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган барлык кирәкле документларны тапшырганда үзара ярдәм итешү зарурлыгы юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>әгәр гариза һәм документларның күчермәләре 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, – турыдан-туры хезмәттәшлек таләп ителми;<br>әгәр гариза һәм документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, – бер көннән дә арттырмыйча.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер хезмәттәшлеге дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гариза бирү, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче http://mtsz.tatarstan.ru | |

| | | |
|---|---|---|
| | сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында алырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы гарызнамә составында күрсәтелми | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча бирелгән очракта) һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документларның электрон документлар рәвешендә күчермәләре Идарәгә (бүлеккә) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре ярдәмендә җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) электрон йөрткечләрдә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза бирүченең гаилә әгъзаларының яки аларның законлы вәкилләренең шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын раслаучы гариза һәм документ гади электрон имза белән имзаланырга тиеш, ә гаризага кушып бирелә торган документлар 63-ФЗ санлы Федераль закон һәм 210-ФЗ санлы Федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьяларында күрсәтелгән таләпләр нигезендә законда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланырга тиеш | 63-ФЗ санлы Федераль закон;<br>210-ФЗ санлы Федераль закон; |

3 бүлектә:
3.4.1 пунктның тугызынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга;
3.4.2 пунктның тугызынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга;
түбәндәге эчтәлекле $1^1$ нче кушымта белән тулыландырырга:

«$1^1$ нче кушымта
Татарстан Республикасы
пенсионерларының аерым категорияләрен
ташламалы шартларда шифаханә-курорт
дәвалавына юллама алу өчен
исәпкә кую буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
____________________муниципаль районындагы
яисә Татарстан Республикасы шәһәр округындагы
Социаль яклау идарәсе (бүлеге) җитәкчесенә
__________________________________ исеменнән,
(Ф.И.А. (соңгысы - булганда))
__________________________________ булган
(гариза бирүченең категориясе)
Паспорт, серия _________ № _________________
Кайчан, кем тарафыннан бирелгән ______________________________
СНИЛС[1] ____________________________________
Тору урыны буенча теркәлү адресы _________
_______________________________________________
_______________________________________________
Фактик тору адресы _______________
_______________________________________________
Телефоннар:
өй: _______________
мобиль: _______________
e-mail:_______________________________________

ГАРИЗА
ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына
юллама белән тәэмин итүгә

Сездән __________________________________________________

[1] Тутыру мәҗбүри түгел

(Ф.И.А. тулысынча (соңгысы - булганда))

_________________ датасыннан 070/у формасы буенча шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен бирелгән белешмә нигезендә ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итүегезне сорыйм.

(дата) (авыру коды)

1. Гаилә составы турында мәгълүмат[2]:

| № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туганлык мөнәсәбәтләре |
|---|---|---|
| 1. | | |
| 2. | | |
| 3. | | |

2. Гариза бирүченең милеге турында белешмәләр[3]:

1. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, мәйданы 40 квадрат метрдан артыграк булган торак урын (торак урын өлеше), ☐ бар ☐ юк

шул исәптән:

1.1. Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның авыр формасы белән авырый торган, законнар нигезендә аның белән бергә яшәү мөмкин булмаган торак урынының мәйданы (шул исәптән фатирдагы изоляцияләнгән аерым торак урынның мәйданы); ☐ бар ☐ юк ☐ мәйдәнын күрсәтерг

1.2 билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыны ☐ ☐

2. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, мәйданы ялгыз яшәгән гариза бирүчегә исәпләгәндә 80 квадрат метрдан артыграк булган торак урын (торак урын өлеше). ☐ бар ☐ юк

3. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, гомуми мәйданы ялгыз яшәүче гражданга исәпләгәндә 40 квадрат метрдан артып киткән, ә ике һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләнең һәр әгъзасына 23 квадрат метрдан артып киткән ике һәм аннан күбрәк торак урыннар (торак урыннарның өлешләре), ☐ бар ☐ юк

шул исәптән:

3.1. Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның авыр ☐ бар ☐ юк ☐ мәйданын

---

[2] Тутыру мәҗбүри түгел

[3] милекнең булуы "V" билгесе белән күрсәтелә, булмавы "X" билгесе белән күрсәтелә

формасы белән авырый торган, законнар нигезендә аның белән бергә яшәү мөмкин булмаган торак урынының мәйданы (шул исәптән фатирдагы изоляцияләнгән аерым торак урынның мәйданы);

3.2 билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыны

бар юк

4. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле һәм торуга яраксыз биналар, төзелмәләр, корылмалар (аларының өлешләре) (транспорт чараларын урнаштыру өчен билгеләнгән күчемсез мөлкәт объектларыннан (гараж, машина урыны), шәхси торак төзелеше яки шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрендә, бакчалы җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмаларыннан, шулай ук әлеге Кушымтаның 4 пунктында саналган объектлардан тыш);

бар юк

5. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, хуҗалык корылмалары булмаган, гомуми мәйданы 40 квадрат метрдан арткан бер яки берничә бакча йорты, дача (бакча) төзелеше объектлары;

бар юк

6. Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән автомобиль, автобус, үзйөрешле машина, пневматик һәм чылбырлы йөрешле механизм, самолет, вертолет, теплоход, яхта, җилкәнле судно, катер, кар мотоциклы, моточана, гидроцикл, үзйөрешсез буксирдагы судно, башка су һәм һава транспорты чарасы (дүрт һәм күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләгә бирелгән (гаилә тарафыннан алынган) җиңел автомобильдән, шулай ук бишттән артык урыны булган автомобильдән тыш);

бар юк

7. Ике һәм аннан күбрәк җиңел автомобиль, шулардан берсенең чыгару елы мөрәҗәгать итү көненә өч елдан артмый (инвалид куллану өчен махсус җиһазландырылган җиңел автомобильдән тыш, дүрт һәм күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләгә бирелгән (гаилә тарафыннан алынган), биштән артык урыны булган җиңел автомобильдән тыш).

бар юк

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль закон нигезендә әлеге гаризада күрсәтелгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, шул исәптән җыюга, төгәлләштерүгә, файдалануга, шәхси мәгълүматлар белән мәгълүмати алмашу системасында өченче затларга тапшыруга ризалыгымны бирәм.

Бирелгән мәгълүматларның һәм документларның дөреслеген раслыйм.

Мәгълүмат алуга риза, шул исәптән ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итү яки ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итүдән баш тарту турында.

Түбәндәге формада хәбәргә алырга ризалык белдерәм:

язмача бу почта адресына: ________________________________________

__________________________________________________________________________________;

СМС-хәбәр белән бу телефонга: ______________________________________________;

электрон документ рәвешендә бу электрон почта адресына: __________________

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» дәүләт мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша: ________________________________________________.

Миңа шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итүгә, шулай ук мәгълүмат бирүгә кагылышлы берәр төрле үзгәрешләр булганда (адрес, телефон һ.б.), бу хакта Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының _______________________ муниципаль районындагы яисә шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) хәбәр итәргә кирәклеге турында хәбәр ителде.

«__» ___________ 20____ ел. _______________ ___________________________________

(имза) (Ф.И.А. (соңгысы - булганда))

Гаризаны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ____________________муниципаль районындагы яисә Татарстан Республикасы шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) белгече кабул итте.

Гариза бирүченең шәхесен раслаучы документтагы белешмәләр тикшерелде.

Гариза белән аңа кушымта итеп бирелгән документлар _____ нөсхәдә "___" ___________№ ______ кабул ителде һәм теркәлде.

«__» ___________ 20__ ел. _____________________ _________________________________

(имза) (белгеч Ф.И.А. (соңгысы - булганда))

_____________________________ кисү сызыгы _______________________________

Расписка

__________________________________________________________ гаризасы

(Ф.И.А. (соңгысы - булганда))

____________________________________________________ юллама бирү өчен

(Ф.И.А. (соңгысы - булганда))

070/у формасы буенча санатор-курорт дәвалавына юллама алу өчен тапшырылган белешмә нигезендә шифаханә-курорт дәвалавына

________________ _____________________________________________________________

(дата) (авыру коды)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

________________________ муниципаль районындагы яисә Татарстан

Республикасы шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) белгече кабул итте.

«__» __________ 20__ ел. ____________________ __________________________________

(имза) (белгеч Ф.И.А. (соңгысы - булганда))

Регламентка 4 нче кушымтада «(муниципаль районда (шәһәр округында) (районда))» сүзләрен «(муниципаль районда яисә шәһәр округында)» сүзләренә алмаштырырга.